

Мордовия Дәүләт Жыены рәисе Владимир Чибиркин Россия Дәүләт Думасынын коммуналь инфраструктура торышы мәсьәләләре буенча «Хокүмәт сәгате»ндә катнашты.
Тобәкләрнен закон чыгаручылары видеоэлемтә буенча утырышка тоташтырылды. Дәүләт Думасы Рәисе Вячеслав Володин торак-коммуналь хужалыкка ярдәм итү бурычы президент тарафыннан остенлекле бурычлар рәтендә билгеләнүен искәртте. «Президент йокләмәләре үтәлергә тиеш. Ул вакытта нәтижә булачак», - дип ассызыклады спикер. Бюджет турындагы закон проектын караганда экономияләнгән акчаларны торак-коммуналь хужалыкны модернизацияләүгә юнәлтергә тәкъдим ителде. Профильле Министр Ирек Фәйзуллин билгеләп үткәнчә, тобәкләрдә тармакны комплексы модернизацияләүне тәэмин итү очен ЖКХ олкәсендә цифрлы чишелешләр кертергә кирәк. «Ресурсларны исәпкә алунын бердәм платформасын булдыру, шулай ук акыллы счетчикларны һәр жирдә куллануны кертү таләп ителә», - диде министр. Ул шулай ук хәбәр иткәнчә, илдәге коммуналь челтәрләрнен 40% тан артыгы алыштыруга мохтаж. Әлеге максатларга «Коммуналь инфраструктураны модернизацияләү» федераль проекты юнәлдерелгән. Ул үз эченә барлык гамәлдәге һәм планлаштырылган ярдәм чараларын алачак. «Тобәкләргә челтәрләрне алыштыру очен барлык финанслау чыганакларынын баланс-лылыгын тәэмин итү буенча зур эш котә», - диде Ирек Фәйзуллин.
«Хокүмәт сәгате»ндә жылыту сезонына әзерлек, шулай ук энергия белән тәэмин итү һәм электр энергиясен куллану мәсьәләләре турында фикер алышынды: бу хакта Россия Энергетика министры вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Евгений Грабчак сойләде. Дәүләт Думасынын профильле комитетлары житәкчеләре һәм фракцияләр вәкилләре торак-коммуналь хужалык



олкәсендәге вәзгыятьне яхшырту чараларын тәкъдим иттеләр. Дәүләт Думасы белән видеоэлемтә вакытында Мордовиянен дәүләт жыелышында Тобәк энергетика һәм торак-коммуналь хужалык министры Александр Голянин булды.
Шул ук атнада, Ол-кәннәр айлыгы кысаларында, Мордовия Дәүләт Жыены рәисе Владимир Чибиркин житәкчелегендә рес-публиканын Дәүләт жыелышында ветераннар советы әгъзалары – элеккеге депутатлар һәм закон чыгару органы аппараты хезмәткәрләре кабат жыелды. Дәүләт Жыены Рәисе Владимир Чибиркин белән алар үзләренен һонәри һәм тормыш тәжрибәсе файдалы булырлык мәсьәләләрне хәл итүдә

фикер алыштылар. Үзара аралашу жинелрәк булсын очен, «Мордовия Республикасы Дәүләт Жыелышы ветераннары» дип аталган мобиль чатларын да булдырганнар. Ветераннар Советы эшчәнлегендә топ юнәлешләрнен берсе, республиканын барлык жәмәгатьчелеге кебек үк, махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм чик буе тобәкләрендә яшәүчеләргә ярдәм итү булып кала. Шул исәптән Курск олкәсенә кирәкле әйберләрне сатып алу һәм жибәрү очен акча жыйганнар.
- Мы благодарны вам за помощь во всенародном деле. Наши земляки воюют на передовой, а мы здесь делаем все возможное, чтобы цели СВО были достигнуты, был обеспечен мир и безопасность нашей страны, - ди Владимир Чибиркин.
Очрашу жылы атмосферада Дәүләт Жыелышында эшләгән еллары турындагы истәлекләр һәм киләчәккә планнар турында фикер алышулар белән узган.

**Наилә НАСЫРОВА әзерләде**